**СОВЕТ**
**Красноборского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Красный Бор авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2019 Красный Бор авылы номер 52-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003, 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007, 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018, 498-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Уставы нигезендә, Красный Бор авыл җирлеге Уставына Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокурорының 28.03.2009 № 02-08-01/51 протестын һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең «Муниципаль хокукый акт проектын карау турында» 25.10.2019, № 02-834ЭП язма мөрәҗәгате буенча тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2.Әлеге карарны дәүләт теркәве өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

4.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы А.Н. Лазарев